КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 ноябрь г.Казань № 1058

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 декабрь, 906 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 декабрь, 906 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 октябрь, 856 нчы; 2013 ел, 24 октябрь, 793 нче; 2014 ел, 20 сентябрь, 669 нчы; 2015 ел, 14 май, 341 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2015 ел, 17 ноябрь, 862 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 781 нче; 2018 ел, 24 август, 708 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2019 ел, 15 май, 395 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы бертип нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы» сүзләрен «башкарма орган» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«башкарма орган эшчәнлегенә җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашыру»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Иҗтимагый Советның бурычлары:

тиешле өлкәдә дәүләт сәясәтен камилләштерүдә катнашу;

башкарма орган тарафыннан карарлар кабул ителгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

башкарма орган эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең хәбәрдар булуын арттыру;

җәмгыятьтә коррупциячел тотышка карата түземсезлек булдыру.»;

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.5 пункт өстәргә:

«2.5. Әлеге максатларга ирешү һәм куелган бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет:

тиешле өлкәдә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

коррупциягә каршы тору эшчәнлегендә катнаша;

«Россия Федерациясендә җәмәгатьчелек контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә башкарма орган тарафыннан эшләнә торган, бу орган каршындагы Иҗтимагый совет утырышында алдан карап тикшерелмичә кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрүне оештыра;

башкарма орган тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын мониторинглауда катнаша;

башкарма органның дәүләт сатып алулары нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша;

дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү буенча конкурс комиссияләре һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләре аттестациясен үткәрү өчен аттестация комиссияләре эшендә катнаша.»;

3.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бу Бертип нигезләмәнең 6.6 пунктында каралган нигезләр булу.»;

3.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый совет әгъзасының мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксынуы барлыкка килгәндә.»;

3.8 пунктта:

беренче абзацта «яки рәисе урынбасары» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «яки рәисе урынбасарына» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.3 пунктның икенче абзацында тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы» сүзләрен тиешле килешләрдәге «башкарма орган» сүзләренә алмаштырырга;

5.4 пунктның икенче абзацында тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы» сүзләрен тиешле килешләрдәге «башкарма орган» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Иҗтимагый советта мәнфәгатьләр конфликты

6.1. Мәнфәгатьләр конфликты – Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынуы үз бурычларын тиешле рәвештә, объектив һәм гадел башкаруга (вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга) йогынты ясый торган яки йогынты ясый алган һәм шул ук вакытта Иҗтимагый советы әгъзасының шәхси кызыксынуы белән Иҗтимагый совет максатлары, бурычлары арасында каршылык барлыкка килә торган яки барлыкка килә алган хәл.

6.2. Иҗтимагый совет әгъзасының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру объективлыгына һәм гаделлегенә йогынты ясый торган яки йогынты ясый алган шәхси кызыксынуы дигәндә Иҗтимагый совет әгъзасы тарафыннан акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокуклары яисә үзе яки өченче затлар өчен хезмәт күрсәтүләр рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

6.3. Иҗтимагый совет әгъзасы барлыкка килгән мәнфәгатьләр конфликты турында яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында бу хакта билгеле булу белән Иҗтимагый совет рәисенә һәм башкарма орган җитәкчесенә язма рәвештә хәбәр итәргә, ә Иҗтимагый совет рәисе бу хакта Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә мәгълүмат бирергә тиеш.

Иҗтимагый совет рәисе барлыкка килгән мәнфәгатьләр конфликты турында яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында бу хакта билгеле булу белән башкарма орган җитәкчесенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

6.4. Иҗтимагый совет әгъзасының мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган Иҗтимагый совет рәисе яки Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча, шул исәптән мәнфәгатьләр конфликты ягы булып торучы Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктатып тору яки туктату турында башкарма орган җитәкчесенә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан билгеләгән тәртиптә тәкъдим кертү юлы белән чаралар күрергә тиеш.

6.5. Иҗтимагый совет рәисе яки Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Иҗтимагый совет эшчәнлегендәге коррупциоген рискларны бәяли һәм Иҗтимагый совет әгъзаларының Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләренә ия эшчәнлектә катнашуын булдырмау максатларында аларны минимальләштерү буенча чаралар күрә.

Иҗтимагый совет әгъзасының Коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләренә ия эшчәнлектә катнашу факты турында билгеле булган Иҗтимагый совет рәисе өч эш көне эчендә бу хакта башкарма орган җитәкчесенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә хәбәр итә.

Иҗтимагый совет рәисенең Коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләренә ия эшчәнлектә катнашу факты турында билгеле булган Иҗтимагый совет әгъзалары өч эш көне эчендә бу хакта башкарма орган җитәкчесенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә хәбәр итә.

6.6. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Иҗтимагый совет әгъзасының Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләренә ия эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүмат алган очракта, Иҗтимагый совет әгъзасының Иҗтимагый совет эшендә катнашуын туктатып тору турында башкарма орган җитәкчесенә тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктатып тору турында башкарма орган җитәкчесе карары башкарма орган боерыгы белән расланырга тиеш.

6.7. Иҗтимагый советы әгъзасының мәнфәгатьләр конфликтын барлыкка килүгә китерә торган хәлләр бетерелмәгән яки Иҗтимагый совет рәисенең Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләренә ия эшчәнлектә катнашу факты расланган очракта, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы башкарма орган җитәкчесенә Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында башкарма орган җитәкчесе карары башкарма орган боерыгы белән расланырга тиеш.

6.8. Иҗтимагый советы әгъзасының мәнфәгатьләр конфликтын барлыкка килүгә китерә торган хәлләр бетерелгән (расланмаган) һәм (яки) Иҗтимагый совет әгъзасының Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләренә ия эшчәнлектә катнашу факты расланмаган очракта, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы башкарма орган җитәкчесенә Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен торгызу турында тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен торгызу турында башкарма орган җитәкчесе карары башкарма орган боерыгы белән расланырга тиеш.».

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына бер ай эчендә иҗтимагый советлар турындагы нигезләмәләрне бу карарга туры китерергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин